Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман Кәләй авыл Советы

КАРАРЫ

19 апрель 2022ел № 39

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл Советының кайбер карарларын гамәлдән чыгару турында

Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Урман Кәләй авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

2008 елның 25 декабрендәге 64 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» гы карары;

2009 елның 29 июлендәге 79 номерлы "Әлмәт муниципаль районы" муниципаль берәмлегенә вәкаләтләрне тапшыру турында»гы карары;

2009 елның 25 ноябрендәге 88б номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 27 февралендәге 185 номерлы "Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 05 маендагы 195 номерлы "Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары ;

2009 елның 16 декабрендәге 90 номерлы "Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары турында»гы карары;

2009 елның 25 ноябрендәге 88 номерлы"Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлеге территориясендә 2010 елга халыкның торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында»гы карары;

2010 елның 26 мартындагы 97 номерлы"Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Урман Кәләй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карары;

2010 елның 03 сентябрендәге 107а номерлы"Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл Советының 2010 елның 26 мартындагы 97 номерлы « Урман Кәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында" гы карары;

2. Әлеге карарны Урман Кәләй авылы Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Урман Кәләй авыл
җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев